**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2023 елның «10» ноябреннән № 38-310

Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәне раслау турында» 2021елның 30 сентябрендәге 14-107 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру үзенчәлекләре турында» 2022 елның 10 мартындагы 336 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 14-107 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 29 декабрендәге 17-136 номерлы, 2023 елның 26 маендагы 34-272 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче кушымтаны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru , «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http// novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының Экология, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияләрне төзекләндерү буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Советының
2021 елның 30 сентябрендәге
14-107 номерлы карары белән
расланган Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
территориясендә муниципаль
торак контроле турындагы нигезләмәгә
2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Советының
2023 елның 26 маендагы 34-272 номерлы;
2023 елның 10 ноябрендәге 38-310 номерлы
карарлары редакциясендә)

Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда контроль чаралар үткәрү өчен нигез буларак кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары

1. Контроль органга көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча хәл ителгән муниципаль торак фондының торак урыннары булган күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышының ике ай рәттән һәм аннан да күбрәк беркетмәләре керү.

2. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Торак кодексының 165 статьясындагы 5 өлеше нигезендә билгеләнә торган урнаштыру тәртибе, рәвешләре, сроклары һәм вакыты нигезендә урнаштырылырга тиешле мәгълүматны өч һәм аннан артык ай дәвамында актуальләштерүнең булмавы.

3. Контрольдә тотылучы зат идарәсендә булган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтнең төзексезлеген бетерү эшләрен башкару өчен ремонт бригадаларын Бердәм диспетчерлык хезмәте мәгълүматы буенча атнага биш мәртәбәдән күбрәк чакыру очраклары.

4. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү документларында күпфатирлы йорт милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдаланганда һәм тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләмен алдагы шундый ук исәп-хисап чоры белән чагыштырганда 50% тан артык арттыру турында белешмәләрнең ачыклануы.